# Сокландыргыч артистлар

## Галиәскәр Камал аристлары белән очрашу (15-16.04.2021 ел)

Г.Камал исемендәге татар академия театры артистлары Яр Чаллы шәһәренә гастрольләр белән килгәч, артистлар безнең гимназия укучылары белән очрашу кичәләренә киләләр. Без бу вакыйганы көтеп алабыз.

Бу юлы да безне онытмадылар, Әсхәт Хисмәтов, Илтөзәр Миңнегалиев, Ләйсән Рәхимова, Ирек Кашапов, Рамил Вәҗиев, Илдус Габдрахманов, вакытларын кызганмыйча, бар эшләрен читкә куеп, безнең белән аралашырга, үз һөнәрләре хакында сөйләргә вакыт таптылар.

Очрашу Булат Сәләховның “Яратылмый калган ярлар” спектакле белән башланды. Аны Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы драмы театры артистлары Энҗе Шиһапова , Чулпан Садыйкова җитәкчелегендәге “Тылсым” театр түгәрәге укучылары куйды. Алар тамашачыны хактан да тылсымладылар. Килгән кунаклар укучыларның уйнауларын бик ошаттылар.

Аннан кичә үз җае белән дәвам итте. Кунакларга Г.Камал театры артистлары катнашында узган очрашуларның фотосурәтләрдән торган елъмасы тәкъдим ителде. Кунаклар тагы да җанланып киттеләр, бик күп артистларның гимназиядә кунак булып китүләренең шаһиты булдылар.

Очрашуны әзерләгән татар теле һәм әдәбияты укытучысы Энҗе Нурисламова кунаклар белән якыннан таныштыра башлады. Безгә килгән артистлар җырчы да, биюче дә, нәфис сүз осталары да ич! Укытучыларга гомере буе рәхмәтле булган Әсхәт абый “Хәтерлим мин әле бүгенгедәй” җырын башкарды .

Илтөзәр абый , тормышчан һәм мавыктыргыч итеп, химия фәнен аңлатты. Мин эчемнән генә “менә нинди шәп укытучы булыр иде!” дип утырдым. Илтөзәр абый кулына гармун алды һәм Ләйсән апа белән “Өйләнәм” спектакленнән бер өзек уйнап күрсәтте. Безгә бик ошады.

Сәхнәгә Илдус Габдрахманов гитара тотып чыгып баскач , без тынып калдык. Ул, гитарада уйный-уйный, чечетка бии башламасынмы! Аның җитезлеге, сыгылмалылыгы! Безнең күзләр камашты.

Рамил Вәҗиев үзенең бәрхеттәй йомшак тавышы белән бик матур итеп шигырь укыды.

Ирек Кашапов “Синең куллар, әнкәй ” җырын башкарды. Зал алкышларга күмелде.

Әлеге очрашу бер мизгел кебек үтеп китте, ләкин аның истәлеге, сокландыргыч артистлар күңелләрдә озак сакланыр.

**(Алия Нурисламова)**






ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ
И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН
2021
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ
ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ


Гимназия №2




Гимназия №2